РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Буа шәһәре

№

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 22 февралендәге 5-29 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 22 февралендәге 5-29 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексына (30.10.2020 №4-2 какары ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 31 нче пунктның 1 нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов